ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
07.05.2026 ел

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 1585

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281.1 статьясы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Федераль дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан, шулай ук федераль дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 мартындагы 208 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләрен кушымтада каралганча раслarга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетның 2013 елның 15 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 413 номерлы карары үз көчен югаткан дип танарга.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә начальнигына Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2026 елның 07 маендагы
1585 номерлы карарына
кушымта

ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫНА КЕРҮЧЕ ЗАТНЫҢ, ШУЛАЙ УК МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕ ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ КЕРЕМНӘРЕ, МӨЛКӘТЕ ҺӘМ МӨЛКӘТИ ХАРАКТЕРДАГЫ ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР ТАПШЫРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

1. Әлеге Кагыйдәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган, әлеге Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба – керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) тапшыру тәртибен билгели.

2. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат (алга таба – муниципаль учреждение) кергәндә барлык чыганаклардан (элекке эш урыны яки сайлаулы вазыйфаны биләү урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен, үзенә милек хокукындагы мөлкәте турында һәм муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында һәм аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча белешмәләр тапшыра.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнеп куела торган вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелгәндә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылмаган очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе мондый вазыйфага билгеләнеп куелган көннән алып 4 ай эчендә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пункты нигезендә шундый белешмәләрне тапшыра.

4. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң киләсе елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча түбәндәгеләрне тапшыра:

- - чыгымнар (хисап чоры) турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр барлык чыганаклардан (акчалата

бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына булган торыш буенча милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

- чыгымнар (хисап чоры), барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) белешмәләр тапшыру өчен нигез булган елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры азагына аларның милек хокукындагы мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

5. Әлеге Кагыйдәләрнең 2, 3 һәм 4 пунктларында каралган белешмәләр муниципаль учреждение өчен бердәнбер гамәлгә куючы булып торучы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлекчәсенә (алга таба - кадрлар бүлекчәсе) тапшырыла.

6. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын я хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән белешмәләрне, әлеге Кагыйдәләрнең 3 яисә 4 пунктларында күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң, бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

7. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын я хаталар булуын ачыклаган очракта, ул белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пункты нигезендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы..

8. Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан әлеге Кагыйдәләр нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

Бу белешмәләр Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә  һәм муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасын билгеләү һәм азат итү вәкаләтләре бирелгән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының  башка вазыйфаи затларына тапшырыла.

9. Вазыйфаи бурычларына керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр белән эшләү кергән кадрлар бүлекчәләре, Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда аларны фаш итүдә яисә файдалануда гаепләнсәләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тоталар.

10. Әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр муниципаль учреждение җитәкчесенең шәхси эшнамәсенә теркәп куела.

Кадрлар бүлекчәсенә үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, мондый белешмәләр күрсәтелгән затка мөрәҗәгать иткән көнне документлары белән бергә язма гаризасы буенча кайтарыла. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында кирәкле белешмәләр кадрлар бүлекчәсендә аларны тапшырган көннән алып бер ел дәвамында саклана,

шуннан соң гамәлдәге законнарда һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый актларында билгеләнгән эш башкару кагыйдәләре буенча юкка чыгарылырга тиеш.